СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Апаз авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**от « 28 » апрель 2023 ел** **№ 109**

**«Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозып бирү әһәмиятсез булса, Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге җирле үзидарә органы депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, сайлап куелган вазыйфаи затына карата җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» Апаз авыл җирлеге Советының 2020 елның 02 июлендәге 188 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Уставы нигезендә Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Апаз авыл җирлеге Советының 2020 елның 02 июлендәге 188 номерлы карары белән расланган үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозып бирү әһәмиятсез булса, Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге җирле үзидарә органы депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, сайлап куелган вазыйфаи затына карата җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Күрсәтелгән мәсьәләне карау өчен нигез булып "Россия

Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 73 өлешендә муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) советка кергән гаризасы тора.»;

2) 4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисенең) Совет тарафыннан аның килүеннән соң өч айдан да соңга калмыйча карала.»;

3) 5 нче пунктның 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Совет утырышы урыны һәм вакыты турында хәбәр ителгән муниципаль вазыйфаны биләүче затның килмәве Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын карауга комачауламый.»;

4) 6 нчы пунктның 1 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасы Совет утырышында Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советы тарафыннан расланган Совет регламентында билгеләнгән тәртиптә карала.»;

5) 7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) гаризасын карау нәтиҗәләре буенча муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чарасын куллану яки җаваплылык чарасын куллланудан баш тарту турында карар кабул ителә.»;

Күрсәтелгән карар регламентта билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) гаризасы кергән депутат тавыш бирүдә катнашмый.

6) 11 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Җаваплылык чарасын куллану яки җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре ул кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә муниципаль вазыйфаны биләүче затка имза астында тапшырыла яки тапшыру турында хәбәр белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) җибәрелә.».

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов

СОВЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609003056